ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2019 Казан шәһәре № 10-155/кс

«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 24.11.2017 № 10-47/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020 елга эчә торган суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга 2018-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 24.11.2017 № 10-47/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 10-125/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2017 № 10-47/кс карарына
1 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 02.12.2019
№ 10-155/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы
«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен
эчә торган суга 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Алабуга муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Три медведя» коттеджлар поселогы кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 34,79 | 36,17 | 36,78 | 36,98 | 36,98 | 38,46 |
| 1.1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 29,48 | 30,65 | 30,65 | 30,82 | 30,82 | 32,05 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.11.2017 № 10-47/кс карарына
2 нче кушымта (Татарстан
Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 02.12.2019
№ 10-155/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы
«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен
эчә торган суга 2018-2020 елларга тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Три медведя» коттеджлар поселогы кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Эчә торган су | 2018 | 886,87 | 1 | - | – | 0,6 |
| | | 2019 | 918,39 | 1 | - | – | 0,6 |
| | | 2020 | 936,49 | 1 | - | – | 0,6 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге